Җир йөзендә тынычлык, дуслык, мәрхәмәтлелек, гаделлек булсын!

# ЧИШМӘ БАШЫ

Гыйнвар , 2025

## *Гыйнвар аенда туган бөек шәхесләребез*

Шагыйрь, драматург ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Илдар Гафур улы Юзеев

Җырчы, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әлфия Авзал кызы Авзалова

Балалар язучысы, шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиков

Балалар язучысы Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәева

Җырчы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Салават Фәтхетдинов

Язучы Шәйхи Маннур

Композитор, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Җәүдәт Фәйзи

Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов

## *Батырлык*

Авыл уртасында һәйкәл тора.
Якташларым анда язылган,
Ватан сугышында үлгәннәргә,
Мәңгелек дан,хәтер салынган
41 дә илне саклау өчен.
Авыллардан чыгып киткәннәр
Күпме ачлык,кан коелып
Үлем юлы алар үткәннәр.
Бөек җиңү килгән 45 тә.
Бу якташлар кире кайтмаган.
Каберләрен җилләр генә белгән
Эзләп-эзләп беркем тапмаган,
Хәтер китабында исемнәре,
Таш диварга уеп язылган.
Авылымның һәр йортында ятим
Кайгы,сагыш,үлем сарылган.
Килик әйдә без һәйкәлләргә,
Гөлләр куйыйк,алдын чистартыйк,
Дөнья матурлыгын биргән өчен
Каберенә эзне суытмыйк,
Якташларыбызны онытмыйк....

## *Һәр көнне игелек кыл...*

Һәрбер авылда да сугышта катнашып вафат булган ветераннарга һәйкәл куелган. Ләкин аның куелуы гына җитми, кешеләр аңа хөрмәт белән карарга тиеш. Һәйкәлләр безнең ата-бабаларыбызның рухлары хөрмәтенә , илне саклаучыларны халык онытмасын, безгә тыныч тормыш бүләк иткән кешеләрне һәрчак истә тотсын өчен куелган.

Тыныч, саф күк йөзе, һәр җиргә дә юл ачык, без нәрсә телибез, шуны эшли алабыз. Боларның барысына да рәхмәт йөзеннән без үзебезнең авылларда һәйкәлләрне чистарттык, аларга керер өчен юл салдык. Мәктәбебезнең барлык укучылары да әлеге чарада актив катнаштылар. Тимурчылар әби-бабайларның ишегалдын, йортлары каршысын көрәделәр.

Өлкәннәрдән рәхмәт сүзләре ишетү безнең өчен бик күнелле булды.

## *27 гыйнвар- “Русиянең хәрби дан көне.*

27 гыйнварда “Русиянең хәрби дан көне. Ленинград блокадасын өзү көне” билгеләнә.

900 көн барган камалышта шәһәрдә 2,5 миллион кеше кала.

Камалышның беренче көннәреннән үк фашистлар шәһәрне вәхшиләрчә бомбага тота башлыйлар. Иң кыены - сугышчыларны һәм шәһәр кешеләрен азык-төлек белән тәэмин итү. Булган запас тиз арада юкка чыга. 1941 елның 2 сентябреннән азык-төлеккә карточкалар кертелә. 1941 елның 25 декабреннән Ленинградта яшәүчеләр: эшләүчеләр - 350 грамм, хезмәткәр, балалар һәм кеше тәрбиясендә булучылар 200 грамм ипи ала башлыйлар. Ашау нормасы биш тапкыр киметелә. Кайгы һәр гаиләгә килә. Әти-әниләренең күз алдында уллары һәм кызлары үлә, балалар ятим кала. Күп гаиләләр тулысы белән үлеп бетәләр. Йортларда, урамнарда, кая карама - үле гәүдәләр, аларны хәтта җирләп тә өлгерә алмыйлар. Әмма бу ленинградлыларны тез чүктерә алмый.

Камалыштагы шәһәрне коткару өчен азык-төлек, корал бердәнбер юл - Ладога күле аша озатыла. Бу - боз каткан күл буйлап узучы данлыклы "Яшәү юлы". Шәһәрдән кешеләрне дә шушы юлдан алып чыгалар. Аннан 152 көн файдаланалар. Нәтиҗәдә йөз меңләгән ленинградлы ач үлемнән йолып калына.
Шәһәр бирешми. Ул үзен геройларча яклый һәм 1944 елның 27 нче гыйварында камалыштан чыга.

# Иҗади бакча

**Гыйнвар бабай**

**Үтеп бара әнә
Гыйнвар бабай,
Кар өстеннән шыгыр-шыгыр атлап.
Сакалларын җилләр җилфердәтә,
Керфекләрен бәсләр сарган ап-ак.**

**Як-ягына борылып карамый ул,
Уе бик тә еракларга киткән.
Иңнәренә аның карлар булып
Шыбыр-шыбыр йолдыз ява күктән.**

**Бара гыйнвар горур гына атлап,
Адымнары авыр һәм дә салмак.
Сакчылары боз-сөңгеләр тотып
Як-ягыннан бара аны саклап.**

**Ф. Яруллин**

**Ак мизгел**

**Яратам мин ап-ак төсне
Бөтен дөнья ап-ак төсле.
Куяннар да ак тун кигән
Каеннар да ак туннан.**

**Бүреккә дә керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.
Шундый якты, шундый
нурлы,
Бөтен дөнья ак кына…
Ап- ак була беләә шулай
Безнең туган як кына.**

**Р. Миңнуллин**

**Авылым кышы.**

**Кайтып киләм мәктәптән
Як-ягыма каранып.
Табигатьнең матурлыгына
Карап барам сокланып.
Әйләнә-тирә ап-ак кар,
Кояш балкый саран гына.
Салкын чеметеп ала битне
Итек эче кар гына...
Кар җем-җем килеп ялтырый
Болыннарда , кырларда.
Бигрәк матур соң табигать
Кышын безнең авылда.**

**Сабирова Азалия,
7 сыйныф**

**Гыйнвар**

**Кар өстендә күпме эз!
Күрмәсәгез, күрегез.
Куян азык эзләгән,
Төлке аны күзләгән.**

**Акмалиев Энгел
1 сыйныф**

**Туган ягым, туган туфрагым.**

Һәркем үзенең туган ягын, туган авылын ярата инде ул. Мин дә. Соң шул саф һавалы, яшел үләнле, кечкенә генә инешле авылны ничек яратмаска кирәк?! Шәһәрдә яшәүче туганнарыбыз да, җайлары булган саен, авылга ашкына, биредәге тынычлык, тынлык, саф һава җәлеп итә аларны.

Без Арча районы Өчиле авылында яшибез, урамыбыз “Тукай урамы” дип атала, тынлык, тынычлык. Ә авыл тирәли иксез - чиксез басу киңлекләре. Алар аерым хуҗалыклар тарафыннан бүленгән, кемдер шунда печән үстерә, ашлык игүчеләр дә бар. Мин әти белән печән чабарга барырга яратам. Сусагач эчәргә дип, әни безгә әйрән ясап җибәрә, ул катыктан ясала. Үзебезнең сыер булгач, катык-сөткә аптырамыйбыз, шөкер. “Аягың лапылдаса, авызың чапылдар” дигән халык мәкален әти гел кабатлый. Җәен печән мул әзерләнсә, кыш чыгулары авыр түгел, аның каравы, үзебезнең экологик чиста ит, сөт, май, эремчек, соңгысыннан әни кортлы май ясый. Тәмле була!

Печән чабарга барырга яратам дигән идем бит әле... Әйе, нинди генә үлән үсми анда: тукранбаш, кыяк үлән, көтүче сумкасы, билчән, эт эчәгесе, тагын әле исемнәрен хәтта әти дә белеп бетермәгән башка үләннәр. Шуларны киптереп, печәнлеккә урнаштыргач, лапас хуш искә чума, терлекләр бик теләп ашый әлеге витаминнар хәзинәсен, шунлыктан сөтне дә дә мул бирәләр.

Игътибар белән карасаң, печән арасында нинди генә бөҗәкләр кайнашмый: әнә кырмыска, камка. Чикерткәне күрү бик җайлы түгел, Аллаһы Тәгалә аны яхшы “маскировка” белән бүләкләгән. Яшел сабак арасыннан тиз генә эзләп табармын димә, чер-чер җыры гына ишетелә үзенең. Бөҗәкләрнең һәрберсе үз-үзен сакларга әзер тора, бер-бер куркыныч тудымы, хәзер, я поса, я пырылдап очып китә. Күбәләкләр дә, бал кортлары да үз итә ул үләннәрне, хуш исле нектардан вакытында авыз итеп, җыеп калырга кирәк. Табигатьнең иркә җан ияләре вакыт кадерен яхшы беләләр: көз хәзер килеп җитә ул, аннан карлы кышы да озаклламый...

Менә шулай бер тәртип , бер гармония белән яши минем туган җирем. Сугышлар булмыйча, табигый һәлакәтләр күрмичә, тормышның кадерен белеп, гел шулай яшәргә язсын иде туган туфрагымда.

Вәлиев Рүзәл, 9 сыйныф

# Ял итәбез бергәләп

## Рәсемнәрдән 7 аерма тап




## Фотокроссворд




## Сканворд




## КӘҖӘ рәсемен тап



Мәктәп яңалыклары

Баш мөхәррир:

Шакирова Ләйсән Мансур кызы

Мөхәррир урынбасарлары:

7 сыйныф укучылары